**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы**
**Теләнче-Тамак авыл җирлеге составына керүче Теләнче Тамак авылында**
**гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

20 ноябрь, 2024 ел № 1

Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль законның 45, 69 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы «Теләнче Тамак авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге уставы, «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының Теләнче Тамак авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче Тамак авыл җирлеге Советының 2019 елның 29 октябрендәге 47/2 номерлы карары нигезендә 2025 елның 20 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча Теләнче Тамак авылында узган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2026 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә Сез ризамы:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү (Теләнче-Тамак авылы Балалар бакчасы һәм Мәктәп урамнары буенча гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү; мәдәният йорты территориясендә балалар мәйданчыгын төзекләндерү, койма сатып алу урнаштыру)

- урамнарны яктырту эшләрен башкару (Теләнче-Тамак торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу)

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Теләнче Тамак авылы Совет урымнда юл ремонты)

- жир асты суларынын (чишмэлэрнен) табигый чыгу урыннарын тозеклэндеру»..

«ӘЙЕ» «ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 728 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 377 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

**«Әйе»** позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 377 кеше тавыш бирде;

**«Юк»** позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены **карар бирде:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. . «2026 елда яшәү урыны буенча Теләнче Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы территориясендә теркәлгән һәр бәлигъ булган кешегә 500 (биш йөз) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 250 (ике йөз илле) сум күләмендә билгеләргә, РФ Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизацияләү, контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, Теләнче Тамак авыл җирлеге территориясендә теркәлгән гаилә әгъзаларын үзара салым буенча взносларны түләүдән азат итәргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

«- торак пункт территориясен төзекләндерү (Теләнче-Тамак авылы Балалар бакчасы һәм Мэктэп урамнары буенча гомуми файдаланудагы территорияне төзекләндерү; мәдәният йорты территориясендә балалар мәйданчыгын төзекләндерү, койма сатып алу урнаштыру)

- урамнарны яктырту эшләрен башкару (Теләнче-Тамак торак пунктында урамнарны яктыртуны ремонтлау өчен электр җиһазлары һәм комплектлау элементлары (яктырткычлар) сатып алу)

- торак пункт чикләрендә җирле билгеләнештәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту ( Теләнче Тамак авылы Совет урымнда юл ремонты)

- жир асты суларынын (чишмэлэрнен) табигый чыгу урыннарын тозеклэндеру».

мәсьәләсе буенча карарны кабул ителгән дип танырга.

3. Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Теләнче-Тамак авыл җирлеге Теләнче Тамак авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче
Теләнче-Тамак авыл җирлеге Башлыгы Р.Ш. Назметдинов